КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 сентябрь г.Казань № 862

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 932 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләүдә сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү һәм аларны үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләү һәм үткәрүне оештыруда сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 932 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 март, 196 нчы; 2019 ел, 29 апрель, 353 нче; 2019 ел, 8 ноябрь, 1026 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә сайлауларны әзерләүдә сайлау комиссияләренә булышлык күрсәтү һәм аларны үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан Ф.С.Габделганиевны, И.М.Безуевскийны, А.Б.Гревцовны, В.Н.Демидовны, Э.Ф.Хәйруллинны, Д.Г.Хәмитовны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Камил кызы Галимованы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы Марат Шамил улы Долговны;

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасының баш суд приставы Әнвәр Фәрит улы Закировны (килешү буенча);

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы Максим Владимирович Скирданы (килешү буенча);

Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы Игорь Владимирович Хвостиковны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры Мидхәт Рәфкать улы Шаһиәхмәтовны;

Э.Д.Хиалеев вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин